КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.12.2025 № 834-П

Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре адресы буенча урнашкан «Геолог В.Д.Шашинга һәйкәл», 1981 ел, ачыкланган мәдәни мирас объектын Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Шашин проспекты адресы буенча урнашкан «Геолог В.Д.Шашинга һәйкәл», 1981 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү, аның территориясе чикләрен һәм аны саклау предметын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының 2025 елның 5 декабрендәге уңай бәяләмәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре адресы буенча урнашкан «Геолог В.Д. Шашинга һәйкәл», 1981 ел, ачыкланган мәдәни мирас объектын Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Шашин проспекты адресы буенча урнашкан «Геолог В.Д. Шашинга һәйкәл», 1981 ел, (объект түре – һәйкәл) региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертергә.
2. Әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Шашин проспекты адресы буенча урнашкан «Геолог В.Д.Шашинга һәйкәл», 1981 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен расларга.
3. Әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Шашин проспекты адресы буенча урнашкан «Геолог

В.Д.Шашинга һәйкәл», 1981 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау предметын расларга.

4. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә күрсәтелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.


5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы Мәдәни
мирас объектларын саклау
комитетының 2025 елның 16
декабрендәге 834-П номерлы
боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Шашин проспекты адресы
буенча урнашкан «Геолог В.Д. Шашинга һәйкәл», 1981 ел,
региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты
**территориясе чикләре**

Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Шашин проспекты адресы буенча урнашкан «Геолог В.Д. Шашинга һәйкәл», 1981 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре картасы (схемасы)




Масштабы 1:1000

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| | - мәдәни мирас объекты территориясе чиге |
| 1 | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең характерлы ноктасы |
| | - мәдәни мирас объекты |
| | - КМБДР белешмәләре буенча җир кишәрлекләре чикләре |

| **16:51:012902:85** | - җир кишәрлегенең кадастр номеры |
|---|---|

Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Шашин проспекты адресы буенча урнашкан «Геолог В.Д. Шашинга һәйкәл», 1981 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең
**текстлы тасвирламасы**

Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Шашин проспекты адресы буенча урнашкан «Геолог В.Д. Шашинга һәйкәл», 1981 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә уза:

| Чикне узу | | Чикне узуның тасвирламасы |
|---|---|---|
| ноктадан | ноктага кадәр | |
| 1 | 2 | 1 ноктасыннан төньяк-көнчыгыш юнәлештә кадастр номеры 16:51:012902:85 булган җир кишәрлеге буйлап 11,02 м ераклыктагы 2 ноктасына кадәр; |
| 2 | 3 | 2 ноктасыннан төньяк-көнчыгыш юнәлештә кадастр номеры 16:51:012902:85 булган җир кишәрлеге буйлап 3,21 м ераклыкта 3 ноктасына кадәр; |
| 3 | 4 | 3 ноктасыннан төньяк-көнчыгыш юнәлештә кадастр номеры 16:51:012902:85 булган җир кишәрлеге буйлап 7,23 м ераклыкта 4 ноктасына кадәр; |
| 4 | 5 | 4 ноктасыннан төньяк-көнчыгыш юнәлештә кадастр номеры 16:51:012902:85 булган җир кишәрлеге буйлап 2,38 м ераклыкта 5 ноктасына кадәр; |
| 5 | 6 | 5 ноктасыннан көньяк-көнчыгыш юнәлештә кадастр номеры 16:51:012902:85 булган җир кишәрлеге буйлап 4,53 м ераклыктагы 6 ноктасына кадәр; |
| 6 | 7 | 6 ноктасыннан көньяк-көнчыгыш юнәлештә кадастр номеры 16:51:012902:85 булган җир кишәрлеге буйлап 2,01 м ераклыктагы 7 ноктасына кадәр; |
| 7 | 8 | 7 ноктасыннан көньяк-көнчыгыш юнәлештә кадастр номеры 16:51:012902:85 булган җир кишәрлеге буйлап 7,36 м ераклыктагы 8 ноктасына кадәр; |
| 8 | 9 | 8 ноктасыннан көньяк-көнбатыш юнәлештә кадастр номеры 16:51:012902:85 булган җир кишәрлеге буйлап 3,10 м ераклыкта 9 ноктасына кадәр; |
| 9 | 1 | 9 ноктасыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә кадастр номеры 16:51:012902:85 булган җир кишәрлеге буйлап 11,35 м ераклыктагы 1 ноктасына кадәр. |

Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Шашин проспекты адресы буенча урнашкан «Геолог В.Д. Шашинга һәйкәл», 1981 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең

**характерлы ноктылары таблицасы**

| Нокта № | Җирле координаталар системасындагы нокта координаталары (МСК-16) | |
|---|---|---|
| | X | Y |
| 1 | 343859.31 | 2326583.40 |
| 2 | 343861.09 | 2326594.28 |
| 3 | 343858.87 | 2326596.61 |
| 4 | 343851.69 | 2326597.46 |
| 5 | 343849.35 | 2326597.90 |
| 6 | 343846.05 | 2326594.79 |
| 7 | 343845.94 | 2326592.78 |
| 8 | 343845.83 | 2326585.42 |
| 9 | 343847.96 | 2326583.16 |
| 1 | 343859.31 | 2326583.40 |

Татарстан Республикасы Мәдәни
мирас объектларын саклау
комитетының 2025 елның 16
декабрендәге 834-П номерлы
боерыгына 2 нче кушымта


Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Шашин проспекты адресы буенча урнашкан «Геолог В.Д. Шашинга һәйкәл», 1981 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын

**саклау предметы***


1. Объектның урнашу урыны Лениногорск шәһәренең үзәк өлешендә, кызыл линия буенча Шашин проспекты буенча.
2. Күләм-киңлек композициясе: планда турыпочмаклы конфигурация; һәйкәлнең өске ноктасы буенча биеклек билгеләре.
3. Пьедестал: ике баскычлы стереобатта шомартылган таш белән тышланган турыпочмаклы пьедестал. Көньяк-Көнчыгыш фасад буенча алтын төстәге зур хәрефләр: «В Д ШАШИН». Төньяк-көнчыгыш фасад буенча кара металл планкаларда алтын төстәге зур хәрефләр: «РӘХМӘТЛЕ БУЫННАРДАН НЕФТЬ СӘНӘГАТЕНЕҢ КҮРЕНЕКЛЕ ЭШЛЕКЛЕСЕНӘ». Көньяк-көнбатыш фасад буенча кара металл планкаларда алтын төстәге зур хәрефләр: «1965-1977 елларда СССР НЕФТЬ СӘНӘГАТЕ МИНИСТРЫ».
4. Һәйкәл: металлдан ясалган, алтын төскә буялган һәйкәл, ул пәлтәсе яткан эскәмиядә утыручы В.Д.Шашинны сурәтли.

*Саклау предметы комплекслы һәм фәнни тикшеренүләр, реставрация эшләре нәтиҗәләре буенча үзгәртелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Шашин проспекты адресы буенча урнашкан «Геолог В.Д. Шашинга һәйкәл», 1981 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау предметы таблицасы

| Т/с | Саклау предметы | Төп элементларны фотофиксацияләү/график материаллар |
|---|---|---|
| 1. | Объектның урнашу урыны Лениногорск шәһәренең үзәк өлешендә, кызыл линия буенча Шашин проспекты буенча | <br>Шартлы билгеләр:<br>- мәдәни мирас объекты<br>1 нче рәсем. Объектның урнашу урыны |
| 2. | Күләм-киңлек композициясе: планда турыпочмаклы конфигурация; һәйкәлнең өске ноктасы буенча биеклек билгеләре | <br>2 нче рәсем. Гомуми күренеше |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | Пьедестал: ике баскычлы стереобатта шомартылган таш белән тышланган турыпочмаклы пьедестал. Көньяк-Көнчыгыш фасад буенча алтын төстәге зур хәрефләр: «В Д ШАШИН» Төньяк-көнчыгыш фасад буенча кара металл планкаларда алтын төстәге зур хәрефләр: «РӘХМӘТЛЕ БУЫННАРДАН НЕФТЬ СӘНӘГАТЕНЕҢ КҮРЕНЕКЛЕ ЭШЛЕКЛЕСЕНӘ». Көньяк-көнбатыш фасад буенча кара металл планкаларда алтын төстәге зур хәрефләр: «1965-1977 елларда СССР НЕФТЬ СӘНӘГАТЕ МИНИСТРЫ» | <br><br>3 нче рәсем. Көнчыгыштан күренеше<br><br><br>4 нче рәсем. Төньяк-көнчыгыштан күренеше |

| | | |
|---|---|---|
| | | <br>5 нче рәсем. Көньяк-көнбатыштан күренеше |
| 4. | Һәйкәл: металлдан ясалган, алтын төскә буялган һәйкәл, ул пәлтәсе яткан эскәмиядә утыручы В.Д.Шашинны сурәтли | <br>6 нчы рәсем. Көнчыгыштан күренеше |